РЕСПУБЛИКА
ТАТАРСТАН

ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ
КОМИТЕТ САБИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН
РЕСПУБЛИКАСЫ

САБА МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

12.03.2020 № 420-п

Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы территориясендә гомумтаралган файдалы казылмалар чыгарганда, шулай ук файдалы казылмалар чыгаруга бәйле булмаган җир асты корылмаларын төзегәндә, җир асты байлыкларыннан файдалануга һәм аларны саклауга муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда тикшерүләр үткәрүнең Административ регламентын раслау турында

“Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, “Дәүләт контролен (күзәтчелеген) һәм муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда юридик затларның һәм шәхси эшмәкәрләрнең хокукларын яклау турында” 2008 елның 26 декабрендәге 294-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Саба муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы территориясендә гомумтаралган файдалы казылмалар чыгарганда, шулай ук файдалы казылмалар чыгаруга бәйле булмаган җир асты корылмаларын төзегәндә, җир асты байлыкларыннан файдалануга һәм аларны саклауга муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда тикшерүләр уздыруның Административ регламентын расларга (кушымта итеп бирелә).

2. Әлеге карарны Интернет челтәрендә - Татарстан Республикасының Хокукый мәгълүматлар турындагы http://pravo.tatarstan.ru рәсми порталында бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы рәисе А.М. Галиуллинга йөкләргә.

Җитәкче М.Р. Ишниязов

Татарстан Республикасы
Саба муниципаль районы
Башкарма комитетының
2020 елның 12 мартындагы
420-п номерлы карары белән
РАСЛАНГАН

**Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы территориясендә гомумтаралган файдалы казылмалар чыгарганда, шулай ук файдалы казылмалар чыгаруга бәйле булмаган җир асты корылмаларын төзегәндә, җир асты байлыкларыннан файдалануга һәм аларны саклауга муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда тикшерүләр уздыруның Административ регламенты**

## 1. Гомуми нигезләмәләр.

1.1. Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы территориясендә оештыру – хокукый формаларына һәм милек рәвешләренә бәйсез рәвештә, юридик затлар, шәхси эшмәкәрләр, шулай ук физик затлар тарафыннан гомумтаралган файдалы казылмалар чыгарганда, шулай ук файдалы казылмалар чыгаруга бәйле булмаган җир асты корылмаларын төзегәндә, җир асты байлыкларыннан файдалануга һәм аларны саклауга муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда тикшерүләр уздыруның Административ регламенты (алга таба – административ регламент).

1.2. Муниципаль контроль объекты булып, ведомствога карамастан һәм милек рәвешенә бәйсез рәвештә, муниципаль берәмлек чикләрендә булган барлык җир асты байлыклары, шул исәптән федераль милектә һәм Татарстан Республикасы милкендә булган җирләр тора.

1.3. Муниципаль контроль Россия Федерациясе Җир кодексы, “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, “Дәүләт контролен (күзәтчелеген) һәм муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда юридик затларның һәм шәхси эшмәкәрләрнең хокукларын яклау турында” 2008 елның 26 декабрендәге 294-ФЗ номерлы Федераль закон һәм Россия Федерациясенең, Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актлары, муниципаль хокукый актлар нигезләмәләре һәм әлеге административ регламентта каралган тәртиптә гамәлгә ашырыла.

1.4. Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы территориясендә муниципаль контрольне Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы башкара.

1.5. Гомумтаралган файдалы казылмалар чыгарганда җир асты байлыкларыннан файдалануга һәм саклауга муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда, шулай ук файдалы казылмалар чыгаруга бәйле булмаган җир асты корылмаларын төзегәндә дәүләт хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары, оешмалар һәм иҗтимагый берләшмәләр, шулай ук гражданнар белән үзара бәйләнештә тора.

## 2. Муниципаль контрольнең максатлары һәм бурычлары.

2.1. Муниципаль контрольнең максатлары булып җир законнарын бозуларны кисәтү, ачыклау һәм булдырмау, шулай ук Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы территориясендә җир асты байлыкларын рациональ, нәтиҗәле файдалануны һәм шартнамәчел йөкләмәләрнең үтәлешен контрольдә тоту тора.

2.2. Муниципаль контрольнең төп бурычлары булып җир законнарын үтәү, юридик, вазыйфаи һәм физик затлар тарафыннан билгеләнгән таләпләрне (нормаларны, кагыйдәләрне, нормативларны) үтәү тора.

2.3. Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы түбәндәгеләрне тикшереп тора :

1) Җир асты байлыкларыннан файдалану таләпләрен үтәү;

2) аренда шартнамәләрен үз вакытында төзү һәм җир кишәрлекләренә хокукларны дәүләт теркәвенә алу;

3) килешүдә билгеләнгән җир асты байлыкларын үзләштерү срокларын юридик һәм физик затлар тарафыннан үтәү;

4) максатчан билгеләнеше һәм рөхсәт ителгән файдалану төре буенча җир асты байлыкларыннан файдалану;

5) җир асты байлыкларыннан файдалану хокукын алу тәртибен үтәү;

6) җир хокукын таныклаучы билгеләнгән тәртиптә рәсмиләштерелгән документлардан башка аларны үз белдеге белән куллануны төшереп калдыручы тәртипне үтәү;

7) җирләрне үз вакытында кире кайтару;

8) җирләрнең торышы турында дөрес белешмәләр бирү;

9) җирләрне максатчан файдалану өчен яраклы халәткә китерү яки туфрак катламын бозып алып барыла торган файдалы казылма ятмаларын (гомумтаралган файдалы казылмаларны да кертеп) эшкәртү, төзелеш, урман әзерләү , тикшерү һәм башка эшләр тәмамланганнан соң аларны рекультивацияләү буенча бурычларны үз вакытында үтәү. Шул исәптән хуҗалык эчендәге һәм үз ихтыяҗлары өчен башкарыла торган эшләр;

10) аренда түләвен вакытында һәм дөрес түләү;

11) закон нигезендә җир кишәрлекләрендә билгеләнгән межалау, геодезия һәм башка махсус билгеләр булу һәм аларның сакланышы;;

12) җир мөнәсәбәтләре өлкәсендә закон бозуларны бетерү һәм җир законнарын үтәү турында таләпләрнең үтәлеше;

13)җирләрдән файдалану мәсьәләләре буенча йөкләнгән бурычлар нигезендә башка функцияләр;

2.4. Муниципаль җир контроле түбәндәге эзлеклелектә башкарыла::

1) тикшерүләрне планлаштыру;

2) тикшерү үткәрүгә әзерлек;

3) тикшерү үткәрү һәм аның нәтиҗәләрен рәсмиләштерү;

4) тикшерү барышында ачыкланган хокук бозу очракларына карата чаралар күрү;

5) җир законнарын бозуларны бетерүне контрольдә тоту.

## 3. Планлы тикшерүләр оештыру һәм үткәрү тәртибе

3.1. Планлы тикшерүне үткәрү предметы булып юридик зат, шәхси эшмәкәр һәм физик зат тарафыннан җир законнары нормаларын һәм муниципаль хокукый актларда билгеләнгән таләпләрне үтәү тора.

3.2. Планлы тикшерүләр өч елга бер тапкырдан да ешрак үткәрелми.

3.3. Планлы тикшерүләр Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе тарафыннан расланган еллык планнар нигезендә үткәрелә.

3.4. Планлы тикшерүләр үткәрүнең еллык планнарында түбәндәге белешмәләр күрсәтелә:

1) юридик затларның (аларның филиалларының, вәкиллекләренең, аерымланган структур бүлекчәләрнең) исемнәре, эшчәнлеге планлы рәвештә тикшерелергә тиешле шәхси эшмәкәрләрнең фамилияләре, исемнәре, аталарының исемнәре, юридик затларның (аларның филиалларының, вәкиллекләренең, аерымланган структур бүлекчәләрнең) урнашу урыннары яисә шәхси эшмәкәрләрнең фактта эшчәнлек алып бару урыннары;

2) һәр планлы тикшерүне үткәрүнең максаты һәм нигезе;

3) һәр планлы тикшерүнең башлану датасы һәм сроклары;

4) конкрет планлы тикшерүне гамәлгә ашыручы муниципаль контроль органы атамасы. Дәүләт контроле (күзәтчелеге) органнары, муниципаль контроль органнары тарафыннан планлы тикшерү уздырганда мондый тикшерүдә катнашучы барлык органнарның исемнәре бергә күрсәтелә.

3.5. Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе тарафыннан расланган планлы тикшерүләр планы кызыксынган затларга аны Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән җиткерелә.

3.6. Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы, планлы тикшерүләр үткәрү елыннан алдагы елның 1 сентябренә кадәр вакыт эчендә, билгеләнгән тәртиптә, “Дәүләт контролен (күзәтчелеген) һәм муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда юридик затларның һәм шәхси эшмәкәрләрнең хокукларын яклау турында” 2008 елның 26 декабрендәге 294-ФЗ номерлы Федераль закон нигезләмәләрен исәпкә алып, Саба районы прокуратурасына планлы тикшерүләр үткәрүнең еллык планы проектын җибәрә. Планлы тикшерүләрне еллык планга кертү өчен нигезләр “Дәүләт контролен (күзәтчелеген) һәм муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда юридик затларның һәм шәхси эшмәкәрләрнең хокукларын яклау турында” 2008 елның 26 декабрендәге 294-ФЗ номерлы Федераль закон белән билгеләнгән.

3.7. Планлы тикшерү үткәрү турында юридик затка, шәхси эшмәкәргә, дәүләт контроле (күзәтчелеге) органы җитәкчесе урынбасары, муниципаль контроль органы җитәкчесе күрсәтмәсенең яисә боерыгының күчермәсен җибәрү юлы белән, аны үткәрү башланганчыга кадәр өч эш көненнән дә соңга калмыйча, көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзаланган һәм юридик затның, шәхси эшмәкәрнең электрон почтасы адресы буенча яисә башка мөмкин булган ысул белән, заказлы почта юлламасы белән һәм (яисә) электрон документлар әйләнеше аша, планлы тикшерүне башлау турында муниципаль контрольне гамәлгә ашыручы орган тарафыннан хәбәр ителә.

3.8. Бер кече эшмәкәрлек субъектына карата планлы күчмә тикшерүне үткәрүнең гомуми вакыты елына кече предприятие өчен илле сәгатьтән һәм микропредприятиеләр өчен унбиш сәгатьтән артмаска тиеш.

3.9. Күчмә планлы тикшерү үткәргән вазыйфаи затларның дәлилләнгән тәкъдимнәре нигезендә катлаулы һәм (яки) озак вакытлы тикшеренүләр, махсус экспертизалар һәм тикшеренүләр үткәрү зарурилыгы белән бәйле аерым очракларда күчмә планлы тикшерүне үткәрү вакыты Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы Рәисе тарафыннан озайтылырга мөмкин, ләкин ул егерме эш көненнән дә күбрәк булырга тиеш түгел, кече предприятиеләргә карата илле сәгатьтән дә, микропредприятиеләргә карата - унбиш сәгатьтән дә артык булырга тиеш түгел.

## 4. Планнан тыш тикшерүләрне оештыру һәм уздыру тәртибе

4.1. Планнан тыш тикшерү үткәрү өчен түбәндәгеләр нигез булып тора:

1) муниципаль хокукый актларда билгеләнгән мәҗбүри таләпләрне һәм (яисә) таләпләрне бозуларны бетерү турында юридик зат, шәхси эшмәкәр тарафыннан элегрәк бирелгән күрсәтмәнең үтәлү срогы тәмамлануы;

2) юридик затка, шәхси эшмәкәргә карата планнан тыш тикшерү үткәрү хокукый статус, махсус рөхсәт (лицензия) бирү, рөхсәт бирү (килештерү) кагыйдәләре белән каралган булса, юридик заттан яисә шәхси эшмәкәрдән эшчәнлекнең аерым төрләрен гамәлгә ашыру хокукына хокукый статус, махсус рөхсәт (лицензия) бирү яисә юридик яктан әһәмиятле бүтән гамәлләрне башкару (килештерү) турында муниципаль контроль органына гариза бирү;

3) юридик затлар, шәхси эшмәкәрләр белән үзара бәйләнешсезлекне тикшереп тору буенча чаралар нәтиҗәләрен анализлау нәтиҗәләре буенча муниципаль контроль органы вазыйфаи затын мотивлаштырылган тәкъдим итү, муниципаль контроль органнарына гражданнардан, шул исәптән шәхси эшмәкәрләрдән, юридик затлардан кергән мөрәҗәгатьләрне, дәүләт хакимияте органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан, массакүләм мәгълүмат чараларыннан килгән түбәндәге мәгълүматларны карау яисә алдан тикшерү:

а) гражданнар тормышына, сәламәтлегенә, хайваннарга, үсемлекләргә, әйләнә-тирә мохиткә, Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектларына (тарих һәм мәдәният һәйкәлләренә), Россия Федерациясе Музей фонды составына кертелгән музей предметларына һәм музей коллекцияләренә, аеруча кыйммәтле, шул исәптән уникаль, Россия Федерациясе Архив фонды документларына (тарихи һәм мәдәни ядкарьләргә),милли китапханә фонды составына керә торган аерым тарихи, фәнни, мәдәни әһәмияткә ия булган документларга зыян китерү куркынычы барлыкка килү , дәүләт иминлеге, шулай ук табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләр куркынычы туганда;

б) гражданнар тормышына, сәламәтлегенә, хайваннарга, үсемлекләргә, әйләнә-тирә мохиткә, Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектларына (тарих һәм мәдәният һәйкәлләренә), Россия Федерациясе Музей фонды составына кертелгән музей предметларына һәм музей коллекцияләренә, аеруча кыйммәтле, шул исәптән уникаль, Россия Федерациясе Архив фонды документларына (тарихи һәм мәдәни ядкарьләргә),милли китапханә фонды составына керә торган аерым тарихи, фәнни, мәдәни әһәмияткә ия булган документларга зыян килү , дәүләт иминлеге, шулай

ук табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләр куркынычы туганда;

в) кулланучылар хокукларын бозу (кулланучылар хокукларын яклау өлкәсендә федераль дәүләт күзәтчелеген гамәлгә ашыручы органга, хокуклары бозылган гражданнарга мөрәҗәгать иткән очракта, мөрәҗәгать итүче үзенең бозылган хокукларын яклауны (торгызуны) сорап юридик затка, индивидуаль эшкуарга мөрәҗәгать иткән очракта һәм мондый мөрәҗәгать каралмаган яисә мөрәҗәгать итүченең таләпләре канәгатьләндерелмәгән очракта);

г) товарларны маркировкалау таләпләрен бозу.

Мәҗбүри таләпләрне бозуга юл куйган зат турында дөрес мәгълүмат булмаганда, мәҗбүри таләпләрне бозу турында җитәрлек мәгълүматлар булмаганда, муниципаль контроль органы кергән мәгълүматны алдан тикшерергә мөмкин. Алдан тикшерү барышында гаризалар һәм мәгълүмат биргән затлардан өстәмә белешмәләр һәм материаллар (шул исәптән телдән тәртиптә) соратып алу буенча чаралар күрелә, дәүләт контроле (күзәтчелеге) органы, муниципаль контроль органы карамагында булган юридик затның, шәхси эшмәкәрнең документларын карау үткәрелә, кирәк булганда, юридик затлар, шәхси эшмәкәрләр белән үзара бәйләнешсез һәм күрсәтелгән затларга мәгълүмат бирү һәм муниципаль контроль органнары таләпләрен үтәү бурычларын йөкләмичә башкарыла торган контрольлек чаралары үткәрелә.Алдан тикшерү кысаларында юридик заттан, шәхси эшмәкәрдән алынган мәгълүматка карата аңлатмалар соратып алынырга мөмкин, ләкин мондый аңлатмаларны һәм башка документларны тапшыру мәҗбүри түгел.

4.2. Муниципаль контроль органына мөрәҗәгать иткән затны билгеләргә мөмкинлек бирми торган мөрәҗәгатьләр һәм гаризалар планнан тыш тикшерү үткәрү өчен нигез була алмый.

Муниципаль контроль органына мөрәҗәгать иткән затны, шулай ук “Дәүләт контролен (күзәтчелеген) һәм муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда юридик затларның һәм шәхси эшмәкәрләрнең хокукларын яклау турында” 2008 елның 26 декабрендәге 294-ФЗ номерлы Федераль законның 10 статьясындагы 2 өлешенең 2 пунктында күрсәтелгән фактлар турында белешмәләр булмаган мөрәҗәгатьләр һәм гаризалар планнан тыш тикшерү үткәрү өчен нигез була алмый.

Мөрәҗәгатьтә яки гаризада бәян ителгән мәгълүмат “Дәүләт контролен (күзәтчелеген) һәм муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда юридик затларның һәм шәхси эшмәкәрләрнең хокукларын яклау турында” 2008 елның 26 декабрендәге 294-ФЗ Федераль законның 10 статьясындагы 2 өлешенең 2 пункты нигезендә планнан тыш тикшерү үткәрү өчен нигез булырга мөмкин булса, муниципаль контроль органының вазыйфаи заты мөрәҗәгать яисә гаризаның авторлыгында нигезле шик тапса, мөрәҗәгать иткән затны билгеләү буенча тиешле чаралар күрергә тиеш. Мөрәҗәгать итүче тарафыннан электрон документлар рәвешендә җибәрелгән мөрәҗәгатьләр һәм гаризалар, мөрәҗәгать итүче тарафыннан мәгълүмати-коммуникацион технологияләр кулланып, мөрәҗәгать итүченең Бердәм идентификацияләү һәм аутентификация системасында мәҗбүри авторизацияләнүен күздә тоткан очракта гына планнан тыш тикшерү үткәрү өчен нигез була ала.

4.3. Юридик затларны, шәхси эшмәкәрләрне планнан тыш тикшерү әлеге административ регламентның 3.6 пунктында күрсәтелгән нигез буенча, мондый юридик затларның, шәхси эшмәкәрләрнең эшчәнлеген гамәлгә ашыру урыны буенча прокуратура органы белән килештерелгәннән соң үткәрелергә мөмкин.

4.4. Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы Рәисенең юридик затка, шәхси эшмәкәргә планнан тыш тикшерү үткәрү турындагы күрсәтмәсенә кул куйган көндә, аны килештерү максатыннан, муниципаль контроль органы көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзаланган электрон документ формасында яисә тапшыру турында белдерү белән заказлы почта аша, юридик зат, шәхси эшмәкәр эшчәнлеген гамәлгә ашыру урыны буенча прокуратура органына планнан тыш күчмә тикшерү үткәрүне килештерү турында гариза җибәрә. Бу гаризага Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы Рәисенең планнан тыш урынга чыгып тикшерү үткәрү турындагы күрсәтмәсе күчермәсе һәм аны үткәрүгә нигез булган документлар теркәлә.

4.5. Планнан тыш тикшерү үткәрү турында юридик затка, шәхси эшкуарга муниципаль контроль органы тарафыннан, аны үткәрү башланганчыга кадәр егерме дүрт сәгать алдан хәбәр ителә.

4.6. Планнан тыш күчмә тикшерүне үткәрү турында, үткәрү нигезләре “Дәүләт контролен (күзәтчелеген) һәм муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда юридик затларның һәм шәхси эшмәкәрләрнең хокукларын яклау турында” 2008 елның 26 декабрендәге 294-ФЗ номерлы Федераль законның 10 статьясындагы 2 өлешенең 2 пунктында күрсәтелгән планнан тыш күчмә тикшерүне үткәрүдән тыш, юридик затка, индивидуаль эшкуарга теләсә нинди үтемле ысул белән тикшерү үткәрелә башлаганчы егерме дүрт сәгать алдан муниципаль контроль органы тарафыннан , шул исәптән, көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзаланган һәм юридик затның, шәхси эшкуарның электрон почта адресы буенча җибәрелгән, әгәр мондый адрес юридик затларның бердәм дәүләт реестрында, шәхси эшмәкәрләрнең Бердәм дәүләт реестрында булса яки элек юридик зат, шәхси эшмәкәр тарафыннан муниципаль контроль органына тәкъдим ителгән булса, электрон документ ярдәмендә дә хәбәр ителә.

## 5. Тикшерүне оештыру тәртибе.

5.1. Тикшерү Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы Рәисе күрсәтмәсе нигезендә үткәрелә. Тикшерү бары тик күрсәтмәдә күрсәтелгән вазыйфаи зат яки вазыйфаи затлар тарафыннан гына үткәрелергә мөмкин.

5.2. Боерык тикшерү үткәрүче Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасының вазыйфаи заты, җитәкчегә, башка вазыйфаи затка яки юридик затның вәкаләтле вәкиленә, шәхси эшмәкәргә, аның вәкаләтле вәкиленә, физик затка хезмәт таныклыклары белән бер үк вакытта тапшырыла. Тикшерелергә тиешле затлар таләбе буенча тикшерүне гамәлгә ашыручы вазыйфаи затлар үз вәкаләтләрен раслаучы мәгълүмат бирергә тиеш.

5.3. Планлы һәм планнан тыш тикшерүләр “Дәүләт контролен (күзәтчелеген) һәм муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда юридик затларның һәм шәхси эшмәкәрләрнең хокукларын яклау турында” Федераль законның 11, 12 статьяларында каралган тәртиптә документар тикшерү һәм (яки) күчмә тикшерү формасында үткәрелә.

5.4. Һәр тикшерүне үткәрү вакыты егерме эш көненнән дә артмаска тиеш.

## 6. Тикшерү нәтиҗәләрен рәсмиләштерү тәртибе

6.1. Тикшерү нәтиҗәләре буенча Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасының вазыйфаи заты тарафыннан ике нөсхәдә акт төзелә (тикшерү актының типлаштырылган формасы Россия Федерациясе Хөкүмәте вәкаләтле федераль башкарма хакимият органы тарафыннан билгеләнә).

6.2. Тикшерү актына мәйданнарны үлчәү схемалары, фототаблицалар, кирәк булган очракта, җир кишәрлеген тикшерү акты, үткәрелгән экспертизалар бәяләмәсе, муниципаль хокукый актларда билгеләнгән мәҗбүри таләпләрне яисә таләпләрне бозган өчен җаваплылык йөкләнә торган юридик зат хезмәткәрләренең, шәхси эшкуарларның һәм физик затларның аңлатмалары, ачыкланган бозуларны бетерү турында күрсәтмәләр һәм тикшерү нәтиҗәләренә бәйле башка документлар яисә аларның күчермәләре теркәлә.

6.3. Тикшерү акты ике нөсхәдә аны тәмамланганнан соң турыдан-туры рәсмиләштерелә, аларның берсе кушымталарның күчермәләре белән җитәкчегә, башка вазыйфаи затка яки юридик затның вәкаләтле вәкиленә, шәхси эшкуарга, аның вәкаләтле вәкиленә тикшерү акты белән танышудан баш тарту турында язма белән яисә танышудан баш тарту турында расписка белән тапшырыла. Җитәкче, башка вазыйфаи зат яисә юридик затның вәкаләтле вәкиле, шәхси эшкуар, аның вәкаләтле вәкиле булмаган очракта, шулай ук тикшерелә торган зат танышу турында яисә тикшерү акты белән танышудан баш тарту турында расписка бирергә баш тарткан очракта акт тапшыру турында хәбәрнамә белән заказлы почта аша җибәрелә, ул муниципаль контроль органы эшендә саклана торган тикшерү актының нөсхәсенә беркетелә. Тикшерелүче затның муниципаль контроль кысаларында электрон рәвештә үзара бәйләнешне гамәлгә ашыру ризалыгы булганда, тикшерү акты әлеге актны төзегән затның җитәкчесенә, башка вазыйфаи затына яки юридик затның вәкаләтле вәкиленә, шәхси эшкуарга, аның вәкаләтле вәкиленә көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзаланган электрон документ рәвешендә җибәрелергә мөмкин. Шул ук вакытта әлеге актны төзегән затның көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы белән имзаланган электрон документ формасында тикшерелә торган затка әлеге документны алуны раслауны тәэмин итүче ысул белән җибәрелгән акт тикшерелүче зат тарафыннан алынган дип санала.

6.4. Тикшерү актын төзү өчен үткәрелгән тикшеренүләр, сынаулар, махсус тикшерүләр, экспертизалар нәтиҗәләре буенча бәяләмәләр алырга кирәк булган очракта, тикшерү акты контроль буенча чаралар тәмамланганнан соң өч эш көненнән дә артмаган срокта төзелә һәм җитәкчегә, башка вазыйфаи затка яисә юридик затның вәкаләтле вәкиленә, индивидуаль эшкуарга, аның вәкаләтле вәкиленә расписка астында тапшырыла яки әлеге актны төзегән затның көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы белән (тикшерелүче затның муниципаль контроль кысаларында электрон формада хезмәттәшлек итүгә ризалыгы булганда) имзаланган электрон документ рәвешендә һәм (яисә) тапшыру турында белдерү белән заказлы почта аша, күрсәтелгән документны алуны тәэмин итә торган ысул белән җибәрелә. Бу чакта күрсәтелгән документны тапшыру турында белдерү һәм (яки) алуны башка раслау муниципаль контроль органы эшендә саклана торган тикшерү акты нөсхәсенә теркәлә.

6.5. Планнан тыш күчмә тикшерү үткәрү өчен аны прокуратура органы белән килештерү таләп ителгән очракта, тикшерү актының күчермәсе тикшерү үткәрү турында карар кабул ителгән прокуратура органына тикшерү акты төзелгән көннән алып биш эш көне эчендә җибәрелә.

## 7. Тикшерү барышында ачыкланган хокук бозулар фактларына карата муниципаль контроль органы вазыйфаи затлары тарафыннан күрелә торган чаралар

7.1. Тикшерү уздырганда юридик зат, шәхси эшмәкәр яки физик зат тарафыннан муниципаль хокукый актларда билгеләнгән мәҗбүри таләпләрне яисә таләпләрне бозу очраклары ачыкланган очракта, тикшерү үткәргән вазыйфаи затлар үз вәкаләтләре чикләрендә түбәндәгеләрне үтәргә тиеш:

1) ачыкланган бозуларга юл куйган затларны җаваплылыкка тарту буенча административ чаралар күрү өчен дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенең территориаль бүлегенә тикшерү материалларын җибәрергә.;

2) ачыкланган җитешсезлекләрне бетерү буенча чаралар күрергә;

3) җир законнарын бозуны бетерү турында күрсәтмәдә билгеләнгән срокта җитешсезлекләрне бетерүне контрольдә тотарга.

## 8. Муниципаль контроль чаралары үткәргәндә җир кишәрлекләре милекчеләренең, җирдән файдаланучыларның, җир биләүчеләрнең һәм җир кишәрлекләрен арендалаучыларның хокуклары, бурычлары һәм җаваплылыгы

8.1. Җир кишәрлекләре милекчеләре, җирдән файдаланучылар, җир хуҗалары һәм җир кишәрлекләрен арендалаучылар яки аларның законлы вәкилләре муниципаль җир контроле буенча чаралар үткәргәндә түбәндәге хокукларга ия:

1) тикшерү үткәргәндә турыдан-туры катнашырга, тикшерү предметына кагылышлы мәсьәләләр буенча аңлатмалар бирергә;

2) тикшерү предметына караган һәм аны бирү әлеге административ регламент һәм башка норматив хокукый актлар белән каралган мәгълүматны алырга;

3) ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында муниципаль контроль органнары тарафыннан башка дәүләт органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан яисә дәүләт органнарына яки җирле үзидарә органнарына буйсынган оешмалардан алынган һәм алар карамагында булган бу документлар һәм (яки) мәгълүмат белән танышырга;

4) ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында соратып алына торган документларны һәм (яки) мәгълүматны Дәүләт контроле (күзәтчелеге) органына, муниципаль контроль органына үз инициативасы буенча тапшырырга;

5) тикшерү нәтиҗәләре белән танышырга һәм тикшерү актында үзенең тикшерү нәтиҗәләре белән танышуы турында, алар белән килешү яки алар белән килешмәү турында күрсәтергә, шулай ук муниципаль контроль органы вазыйфаи затларының аерым гамәлләре белән танышырга ;

6) Россия Федерациясе законнары нигезендә административ һәм (яисә) суд тәртибендә тикшерү үткәргәндә юридик затның, шәхси эшмәкәрнең хокукларын бозуга китергән дәүләт контроле (күзәтчелеге) органы, муниципаль контроль органы вазыйфаи затларының гамәлләренә (гамәл кылмауларына) шикаять бирергә.

7) Россия Федерациясе Президенты каршындагы Эшкуарлар хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкилне яисә Татарстан Республикасында Эшкуарлар хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкилне тикшерүдә катнашырга җәлеп итәргә.

8.2. Җир кишәрлекләре милекчеләре, җирдән файдаланучылар, җир хуҗалары һәм җир кишәрлекләрен арендалаучылар түбәндәгеләрне эшләргә бурычлы:

1) муниципаль җир контроле буенча чаралар үткәргәндә үзләренең яки вәкаләтле вәкилләренең булуын тәэмин итәргә;

2) җир кишәрлекләренә хокуклар турында документларны, җирләрдән файдалану һәм саклау мәсьәләләрен җайга салучы проект-техник һәм башка материалларны тапшырырга;

3) күрсәтелгән чараларны үтәгәндә муниципаль җир контроле чараларын оештыруда һәм үткәрүдә ярдәм күрсәтергә.

8.3. Юридик затлар, аларның җитәкчеләре, башка вазыйфаи затлар, юридик затларның вәкаләтле вәкилләре, шәхси эшмәкәрләр, аларның вәкаләтле вәкилләре, тикшерүләр үткәрүгә нигезсез комачаулаган хокук бозулар җибәргән очракта һәм (яисә) тикшерүләр үткәрүдән качып йөрүче һәм (яисә) билгеләнгән вакытка дәүләт контроле (күзәтчелеге) органнары, муниципаль контроль органнарының муниципаль хокукый актларда билгеләнгән хокук бозуларны бетерүгә бәйле мәҗбүри таләпләрне яисә таләпләрне бетерү турындагы күрсәтмәләрен үтәмәгән физик затлар Россия Федерациясе законнары нигезендә җаваплы.

## 9. Муниципаль контрольне гамәлгә ашыручы вазыйфаи затларның хокуклары һәм бурычлары

9.1. Муниципаль җир контролен гамәлгә ашыру буенча йөкләнгән бурычларны үтәү өчен үз компетенциясе чикләрендә муниципаль контрольне гамәлгә ашыручы вазыйфаи зат түбәндәгеләрне эшләргә хокуклы:

– Россия Федерациясе законнарында һәм әлеге административ регламентта билгеләнгән тәртиптә хезмәт таныклыгын күрсәткән вакытта контроль объектларына йөрергә һәм тикшерергә;

– тикшерү нәтиҗәләре буенча җир законнарын үтәүне тикшерү актларын төзергә;

– муниципаль җир контролен гамәлгә ашыруга комачаулаучы гамәлләрне булдырмауда яисә туктатуда, шулай ук җирләрдән файдалануда гаепле гражданнарның шәхесләрен билгеләүдә ярдәм сорап Эчке эшләр органнарына мөрәҗәгать итәргә;

– бердәм дәүләт реестрыннан физик затлар, шәхси эшмәкәрләр һәм юридик затлар турында мәгълүматны һәм мөлкәтнең торышы, алардан файдалану һәм саклау турында материалларны, шул исәптән муниципаль берәмлек территориясендә

контрольне гамәлгә ашыру өчен кирәкле булган мөлкәткә хокукларны раслаучы документларны мөстәкыйль рәвештә сорарга һәм алырга;

– ачыкланган җитешсезлекләрне бетерү һәм гаепле затларны җаваплылыкка тарту буенча чаралар күрү турында мәсьәләләрне хәл итү өчен прокуратура һәм эчке эшләр органнарына мөрәҗәгать итәргә кирәк;

– гаепле затларны административ җаваплылыкка тарту мәсьәләсен карау өчен, гамәлдәге законнарны бозу турындагы материалларны, контрольлек функцияләрен гамәлгә ашыручы башкарма хакимиятнең дәүләт органнарына җибәрергә ;

– Федераль салым хезмәте инспекциясенә муниципаль җир контролен гамәлгә ашыру өчен кирәкле барлык сорауларны җибәрергә һәм теләсә нинди мәгълүматны алырга;

– Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан, Башкарма комитет структурасына керүче органнардан, милекнең барлык рәвешләрендәге оешмалардан, белешмәләрдән һәм үз функцияләрен гамәлгә ашыру өчен кирәкле башка документларны сорарга һәм алырга;

- җир кишәрлекләренең торышы, алардан файдалану турында белешмәләр һәм материаллар, шул исәптән муниципаль җир контролен гамәлгә ашыру өчен кирәкле җиргә хокукны раслаучы документларны түләүсез алырга.

9.2. Муниципаль җир контролен гамәлгә ашыручы вазыйфаи зат тикшерү уздырганда түбәндәгеләрне эшләргә бурычлы:

1) муниципаль хокукый актларда билгеләнгән мәҗбүри таләпләрне һәм таләпләрне бозуларны кисәтү, ачыклау һәм булдырмау буенча Россия Федерациясе законнары нигезендә бирелгән вәкаләтләрне үз вакытында һәм тулы күләмдә үтәргә.;

2) Россия Федерациясе законнарын, Татарстан Республикасы законнарын һәм муниципаль хокукый актларны, физик затларның, юридик затларның һәм шәхси эшмәкәрләрнең хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен үтәргә;

3) Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең аны үткәрү турындагы күрсәтмәсе нигезендә, аны билгеләү буенча тикшерү үткәрергә;

4) хезмәт бурычларын үтәгән вакытта гына тикшерү уздырырга, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы Рәисе күрсәтмәсенең күчермәләре, әлеге административ регламентта каралган очракларда, тикшерү үткәрүне килештерү турындагы документның күчермәләре, хезмәт таныклыкларын күрсәткәндә генә күчмә тикшерүне үткәрергә.;

5) тикшерү уздырганда җитәкчегә, башка вазыйфаи затка яисә юридик затның вәкаләтле вәкиленә, индивидуаль эшкуарга, аның вәкаләтле вәкиленә тикшерү үткәргәндә катнашырга һәм тикшерү предметына караган мәсьәләләр буенча аңлатмалар бирергә комачауламаска;

6) тикшерү уздырганда катнашучы җитәкчегә, башка вазыйфаи затка яисә юридик затның вәкаләтле вәкиленә, шәхси эшкуарга, аның вәкаләтле вәкиленә тикшерү предметына караган мәгълүмат һәм документлар тапшырырга;

7) җитәкчене, башка вазыйфаи затны яки юридик затның вәкаләтле вәкилен, шәхси эшкуарны, аның вәкаләтле вәкилен тикшерү нәтиҗәләре белән таныштырырга;

8) җитәкчене, бүтән вазыйфаи затны яки юридик затның вәкаләтле вәкилен, индивидуаль эшкуарны, аның вәкаләтле вәкилен ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында алынган документлар һәм (яки) мәгълүмат белән таныштырырга.;

9) ачыкланган бозулар фактлары буенча күрелә торган чараларны билгеләгәндә ачыкланган хокук бозуларның авырлыгын, кешеләрнең гомере, сәламәтлеге өчен, хайваннар, үсемлекләр, әйләнә-тирә мохит өчен, Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектларына (тарих һәм мәдәният һәйкәлләренә), Россия Федерациясе Музей фонды составына кертелгән музей предметларына һәм музей коллекцияләренә, аеруча кыйммәтле, шул исәптән Россия Федерациясе Архив фондының уникаль документларына, Милли китапханә фонды составына керүче аеруча тарихи, фәнни, мәдәни әһәмияткә ия документларга, дәүләт иминлегенә, табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләргә куркынычлыгының туры килүен исәпкә алырга, шулай ук гражданнарның, шул исәптән шәхси эшкуарларның, юридик затларның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен нигезсез чикләүгә юл куймаска;

10) Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә юридик затлар, шәхси эшмәкәрләр тарафыннан шикаять белдергәндә үз гамәлләренең нигезле булуын расларга.;

11) “Дәүләт контролен (күзәтчелеген) һәм муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда юридик затларның һәм шәхси эшкуарларның хокукларын яклау турында ” (2019 елның 2 августына үзгәрешләр белән) (2020 елның 1 гыйнварыннан гамәлдә булган редакциясендә) 2008 елның 26 декабрендәге 294-ФЗ номерлы Федераль законда һәм әлеге административ регламентта билгеләнгән тикшерүләрне үткәрү срокларын үтәргә;

12) юридик заттан, шәхси эшкуардан Россия Федерациясе законнарында каралмаган документларны һәм башка белешмәләрне таләп итмәскә.;

13) җитәкче, башка вазыйфаи зат яисә юридик затның вәкаләтле вәкиле, шәхси эшкуар, аның вәкаләтле вәкиленең үтенече буенча күчмә тикшерү уздырыр алдыннан аларны аның нигезендә тикшерү үткәрелә торган административ регламент нигезләмәләре (ул булганда) белән таныштырырга;

14) юридик затта, шәхси эшмәкәрдә булган очракта, тикшерүләрне исәпкә алу журналында үткәрелгән тикшерү турында язманы гамәлгә ашырырга.

9.3. Тикшерү уздырганда муниципаль контроль органының вазыйфаи затлары түбәндәгеләрне эшләргә хокуклы түгел:

1) әгәр мондый таләпләр муниципаль контроль органы вәкаләтләренә керми икән, әлеге вазыйфаи затлар исеменнән гамәлдә була торган мәҗбүри таләпләрнең һәм таләпләрнең үтәлешен тикшерергә.;

2) СССР һәм РСФСР башкарма хакимияте органнарының норматив хокукый актларында билгеләнгән таләпләрнең үтәлешен, шулай ук аларны куллану мәҗбүрилеге Россия Федерациясе законнарында каралмаган норматив документлар таләпләренең үтәлешен тикшерергә ;

3) Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә басылып чыкмаган муниципаль хокукый актларда билгеләнгән мәҗбүри таләпләрнең һәм таләпләрнең үтәлешен тикшерергә. ;

4) “Дәүләт контролен (күзәтчелеген) һәм муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда юридик затларның һәм шәхси эшкуарларның хокукларын яклау турында” 2008 елның 26 декабрендәге 294-ФЗ номерлы Федераль законның 10 статьясындагы 2 өлешенең 2 пунктындагы “б” пунктчасында каралган нигез буенча, мондый тикшерүне

үткәрү очрагыннан тыш,җитәкче, башка вазыйфаи зат яисә юридик затның вәкаләтле вәкиле, шәхси эшкуар, аның вәкаләтле вәкиле булмаганда, планлы яки планнан тыш күчмә тикшерүне гамәлгә ашырырга, шулай ук җир кишәрлекләре милекчеләренә, җирдән файдаланучыларга, җир биләүчеләренә һәм җир кишәрлекләрен арендалаучыларга тиешенчә хәбәр итү очракларында җир законнары таләпләрен үтәүне тикшерергә;

5) әгәр тикшерү объектлары булып тормаса яки тикшерү предметына карамаса, Документлар, мәгълүмат, продукция үрнәкләрен, әйләнә-тирә мохит объектларын һәм җитештерү тирәлеге объектларын тикшерү пробаларын бирүне, шулай ук мондый документларның оригиналларын алуны таләп итәргә;

6)милли стандартларда билгеләнгән нормадан артып киткән күләмдә, күрсәтелгән үрнәкләрне сайлап алу турында беркетмәләр рәсмиләштермичә, аларны тикшерү, сынаулар, үлчәүләр үткәрү өчен продукция үрнәкләрен, әйләнә-тирә мохит объектларын һәм җитештерү тирәлеге объектларын тикшерү пробаларын, билгеләнгән формадагы пробаларны, илкүләм стандартларда билгеләнгән нормадан артып киткән күләмдә , алар үз көченә кергән көнгә кадәр гамәлдә булган башка норматив техник документлар, тикшеренүләр, сынаулар, үлчәүләрнең үрнәкләрен, пробаларын һәм методларын сайлап алу кагыйдәләре, аларны тикшерү, сынаулар, үлчәүләр, техник регламентлар белән яисә аларның үз көченә кергәнчегә кадәр гамәлдә булган башка норматив техник документлар, тикшеренүләр, сынаулар, үлчәү кагыйдәләре һәм методлары белән сайлап алырга;

7) тикшерү уздыру нәтиҗәсендә алынган һәм ,Россия Федерациясе законнарында каралган очраклардан тыш, дәүләт, коммерция, Хезмәт, закон тарафыннан саклана торган башка серне тәшкил итүче мәгълүматны таратырга ;

8) тикшерүне үткәрүнең билгеләнгән срокларыннан арттырып җибәрергә;

9) юридик затларга, шәхси эшмәкәрләргә аларның хисабына контроль буенча чаралар үткәрү турында күрсәтмәләр яки тәкъдимнәр бирергә;

10) юридик заттан, шәхси эшкуардан, Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнгән исемлеккә кертелгән башка дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм дәүләт органнары яки дәүләт органнары һәм җирле үзидарә органнарына караган оешмалар карамагындагы рөхсәт документларын да кертеп, документлар һәм (яисә) мәгълүмат бирүне таләп итәргә.;

11) юридик заттан, шәхси эшмәкәрдән тикшерү үткәрү датасына кадәр документлар, мәгълүмат бирүне таләп итәргә. Муниципаль контроль органы, тикшерү үткәрү турында боерык яки күрсәтмә кабул ителгәннән соң, тикшерү үткәрү турында кирәкле документларны һәм (яки) мәгълүматны ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында соратып алырга хокуклы.

## 10. Тикшерү уздырганда вазыйфаи затларның җаваплылыгы.

10.1. Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасының вазифаи затлары тиешле функцияләрне, хезмәт вазыйфаларын тиешенчә үтәмәгән, тикшерү үткәргәндә хокукка каршы гамәлләр кылган (гамәл кылмаган) очракта Россия Федерациясе законнары нигезендә җаваплы булалар.

10.2. Россия Федерациясе законнарын бозуда гаепле вазыйфаи затларга карата кабул ителгән чаралар турында ,мондый чаралар кабул ителгән көннән соң ун көн эчендә, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы хокуклары һәм (яки) законлы мәнфәгатьләре бозылган юридик затка, шәхси эшмәкәргә, физик затка, юридик затка язма рәвештә хәбәр итәргә тиеш.

## 11. Вазыйфаи затларның гамәлләренә (гамәл кылмауларына) шикаять бирү

11.1. Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы һәм аның вазыйфаи затлары гамәлләренә (гамәл кылмауларына) шикаять белдерү турындагы гариза Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә каралырга тиеш.

## 12. Муниципаль җир контролен гамәлгә ашыручы вазыйфаи затларның карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) шикаять бирүнең судка кадәр (судтан тыш) тәртибе

12.1. Мөрәҗәгать итүчеләр вазыйфаи затларның судка кадәр (судтан тыш) тәртиптә карарларына, гамәлләренә (гамәл кылмауларына) шикаять бирергә хокуклы.

12.2. Мөрәҗәгать итүченең вазыйфаи затларның карарларына, гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаять бирү турында кергән мөрәҗәгате судка кадәр (судтан тыш) шикаять бирү процедурасын башлау өчен нигез булып тора.

12.3. Шикаять бирү тәртибенә карата таләпләр: шикаять язмача кәгазьдә, электрон формада район Башкарма комитетына яисә шәхси кабул итү барышында телдән тапшырыла;

Башкарма комитет тарафыннан кабул ителгән карарларга шикаять Башкарма комитет җитәкчесенә тапшырыла.;

палата рәисенең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) шикаять район Башкарма комитеты җитәкчесенә, Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасарына бирелә.;

мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасының вазыйфаи затларының гамәлләренә (гамәл кылмауларына) шикаять палата рәисенә тапшырыла;

шикаять почта аша, күпфункцияле үзәк аша, Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрен, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының рәсми сайтын, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең (функцияләрнең) бердәм порталын яки дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең (функцияләрнең) региональ порталын кулланып, шулай ук мөрәҗәгать итүченең шәхси кабул итү вакытында кабул ителергә мөмкин.

12.4. Граждан үзенең язма мөрәҗәгатендә мәҗбүри рәвештә язма мөрәҗәгатен җибәрә торган җирле үзидарә органының атамасын яисә тиешле вазыйфаи затның фамилиясен, исемен, атасының исемен, яисә тиешле затның вазыйфасын , шулай ук үз фамилиясен, исемен, әтисенең исемен (соңгысы – булган очракта), җавап җибәрелергә тиешле почта адресы, мөрәҗәгатьне яңадан җибәрү турында белдерү күрсәтә, тәкъдим, гариза яки шикаятьнең асылын бәян итә, шәхси имзасын һәм датасын куя.

Мөрәҗәгать итүче тарафыннан аның шикаятьтә бәян ителгән дәлилләрен раслаучы документлар яки аларның күчермәләре тапшырылырга мөмкин. Бу очракта шикаятьтә аңа кушып бирелә торган документлар исемлеге китерелә.

Җирле үзидарә органнарына яисә вазыйфаи затка электрон документ рәвешендә кергән мөрәҗәгать "Россия Федерациясе гражданнары мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе турында" 2006 елның 2 маендагы 59-ФЗ номерлы Федераль законда билгеләнгән тәртиптә каралырга тиеш. Мөрәҗәгатьтә гражданин үз фамилиясен, исемен, атасының исемен (соңгысы – булган очракта), җавап, мөрәҗәгатьне яңадан үзгәртү турында хәбәр җибәрелергә тиешле электрон почта адресын мәҗбүри рәвештә күрсәтә. Граждан мондый мөрәҗәгатькә кирәкле документларны һәм материалларны электрон формада теркәргә хокуклы.

12.5. Мөрәҗәгать итүче шикаятьне нигезләү һәм карау өчен кирәкле мәгълүмат һәм документлар алуга хокуклы.

12.6. Мөрәжәгать итүченең шикаяте керү көнендә теркәлә һәм мэриядә теркәлгән көннән 15 көн эчендә карала.

12.7. Телдән шикаятьнең эчтәлеге гариза бирүченең шәхси карточкасына кертелә . Әгәр телдән шикаятьтә бәян ителгән фактлар һәм хәлләр күренеп тора һәм өстәмә тикшерү таләп итми икән, шикаятькә җавап, мөрәҗәгать итүче ризалыгы белән, мөрәҗәгать итүченең шәхси кабул итү барышында телдән бирелергә мөмкин. Калган очракларда шикаятьтә куелган сорауларның асылы буенча язмача җавап бирелә.

12.8. Шикаятьне карау нәтиҗәләре буенча мөрәҗәгать итүченең таләпләрен канәгатьләндерү турында яки таләпләрне канәгатьләндерүдән баш тарту турында карар кабул ителә, бу хакта ,карар кабул ителгән көннән соң килүче көннән дә соңга калмыйча, мөрәҗәгать итүчегә шикаятьне карау нәтиҗәләре турында дәлилләнгән җавап җибәрелә.

12.9. Мөрәҗәгатькә җавап җирле үзидарә органнарына яисә вазыйфаи затка электрон документ формасында кергән мөрәҗәгатьтә күрсәтелгән электрон почта адресы буенча электрон документ формасында җибәрелә, һәм җирле үзидарә органына яисә вазыйфаи затка язмача рәвештә кергән мөрәҗәгатьтә күрсәтелгән почта адресы буенча язма рәвештә җибәрелә. Моннан тыш, җирле үзидарә органына яисә вазыйфаи затка кергән, билгесез затлар даирәсе мәнфәгатьләренә кагылышлы тәкъдим, гариза яки шикаятьне үз эченә алган мөрәҗәгатькә, аерым алганда, билгесез затлар даирәсенә карата чыгарылган суд карарына шикаять белдерелә торган мөрәҗәгатькә, суд карарына шикаять бирү тәртибен аңлатып җибәрелгән җавап, "Россия Федерациясе гражданнары мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе турында" 2006 елның 2 маендагы 59-ФЗ номерлы Федераль законның 6 статьясындагы 2 өлеше таләпләрен үтәп, "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге җирле үзидарә органының рәсми сайтында урнаштырыла ала.

12.10. Әгәр язма рәвештә шикаять тексты укылуга бирелмәсә, шикаятькә җавап бирелми һәм ул үз компетенциясе нигезендә дәүләт органына, җирле үзидарә органына яисә вазыйфаи затка карау өчен җибәрелергә тиеш түгел, бу хакта, шикаять теркәлгән көннән соң биш көн эчендә, аның фамилиясе (исеме) һәм почта адресы яки электрон почта адресы укылуга тапшырылса, шикаять җибәргән мөрәҗәгать итүчегә хәбәр ителә.

Шикаять текстында әдәпсез яисә мәсхәрәле гыйбарәләр, вазыйфаи затның, шулай ук аның гаилә әгъзаларының тормышына, сәламәтлегенә һәм мөлкәтенә янаулар булса, вазыйфаи зат шикаятьне анда куелган сорауларның асылы буенча җавапсыз калдырырга һәм шикаять җибәргән мөрәҗәгать итүчегә хокуктан явызларча файдалану

ярамаганлыгы турында хәбәр итәргә хокуклы.

Шикаять текстында суд карарына шикаять бирү турындагы мәсьәлә куелса, шикаять мөрәҗәгать итүчегә әлеге суд карарына шикаять бирү тәртибен аңлатып, аны теркәгән көннән җиде көн эчендә кире кайтарыла.

Әгәр шикаятьнең текстында элегрәк җибәрелгән шикаятьләргә бәйле рәвештә мөрәҗәгать итүчегә асылы буенча язма рәвештә күп тапкырлар җаваплар бирелгән сорау булса һәм шул ук вакытта шикаятьтә яңа дәлилләр яисә хәлләр китерелмәсә, күрсәтелгән шикаять һәм элегрәк җибәрелгән шикаятьләр бер үк вазыйфаи затка юлланган булса, шикаять юлланган мэриянең вазыйфаи заты чираттагы шикаятьнең нигезсез булуы һәм мөрәҗәгать итүче белән әлеге мәсьәлә буенча язышуны туктату турында карар кабул итәргә хокуклы. Бу карар турында шикаять җибәргән мөрәҗәгать итүчегә хәбәр ителә.

Әгәр язма шикаятьтә шикаять җибәргән мөрәҗәгать итүченең фамилиясе (исеме), почта адресы (урнашу урыны), җавап җибәрелергә тиешле электрон почта адресы күрсәтелмәгән булса, шикаятькә җавап бирелми. Әгәр шикаять текстында әзерләнә, эшләнә яисә бөтенләй хокукка каршы килә торган гамәл турында, шулай ук хокукка каршы килә торган гамәлне әзерләүче, кылучы яисә кылган зат турында белешмәләр булса, шикаять аның компетенциясе нигезендә дәүләт органына җибәрелергә тиеш.